## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

### Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә Байлангар авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

03 декабрь, 2024 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылы гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:
2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән: 1 төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар),18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналар, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала»1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

1. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре; су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре);

**- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (Байлангар авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, Байлангар авылы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре; Совет урамы тыкрыгын төзү, карап тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Совет урамы тыкрыгын төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (массакүләм ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары) һәм алар янәшәсендәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм

урнаштыру, проект-смета документлары, массакүләм ял итү урыннарын урнаштыру, карап тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

- **традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма тоту, ремонтлау** (зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, эш кораллары һәм инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау**(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**(Байлангар авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш һәм асфальт салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (Байлангар авылында автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре)

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Байлангар авылы чишмәсен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материаллар сатып алу, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу**

3. Әлеге карарны Байлангар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Байлангар авыл җирлеге
башлыгы: И.Ф.Каримуллин

СОВЕТ БАЙЛАНГАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЙЛАНГАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607752814
ИНН 1623001621